СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 208 от 09.04.2018

на № ________ от _____________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы депутатларының, җирле үзидарә органнарының сайлап куела торган вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезләмә

Хезмәткә түләүне камилләштерү, һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы депутатларының, җирле үзидарә органнарының сайлап куела торган вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезләмәне расларга (теркәлә).

2. Авыл җирлегендәге муниципаль хезмәт вазыйфаларына караган кече төркем белгеченең вазыйфаи хезмәт хакын 11 163 сум күләмендә расларга.

3. Саба муниципаль районы Башлыгының, Саба муниципаль районында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, җирле үзидарәнең сайлап куела торган вазыйфаи затларының, Саба муниципаль районы Контроль-исәп палатасы рәисенең айлык акчалата бүләкләү күләмен 1нче кушымта нигезендә расларга.

4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының чираттагы финанс елына бюджет фаразын төзегәндә (чираттагы финанс елы һәм план чоры) әлеге карар нигезләмәрен кулланырга

5. Үз көчен югалкан дип танырга:

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарының сайлап куела торган вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында” 22.12.2010 ел 23нче карарын;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарының сайлап куела торган вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында” 22.12.2010 ел 23нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарының сайлап куела торган вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында” 23.06.2014 ел 256нчы карарын;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Контроль-исәп палатасы рәисенә акчалата түләү күләме турында” 25.02.2016 ел 37нче карарын;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарының сайлап куела торган вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында” 16.12.2016 ел 84нче карарын;

6. Әлеге карар 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

7. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарына, җирле үзидарә органнары депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында яңа Нигезләмәне исәпкә алып, 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла торган яңа штат расписаниеләре расларга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов

СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РАСЛАНДЫ
Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Советының
09.04.2018 ел, 208 номерлы карары белән

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнары депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында**
**Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. Әлеге Нигезләмә 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында” 2018 ел, 28 март, 182 нче карары, “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайлап куела торган органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлап куела торган вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында” 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставы нигезендә һәм хезмәт хакының стимуллаштыру ролен көчәйтү, хезмәтнең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын арттыру, хезмәткәрләрнең Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы (алга таба - муниципаль район) җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә керткән шәхси хезмәтен бәяләү максатында гамәлгә кертелә.

## 2. Муниципаль район Башлыгын, муниципаль район Башлыгы урынбасарын, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларын, сайлап куела торган вазыйфаи затларын, муниципаль район Контроль-исәп палатасы рәисен айлык акчалата бүләкләү

2.1. Муниципаль район Башлыгын, муниципаль район Башлыгы урынбасарын, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларын, сайлап куела торган вазыйфаи затларын, муниципаль район Контроль-исәп палатасы рәисен айлык акчалата бүләкләү Саба муниципаль районы Советы карары белән билгеләнә.

2.2. Муниципаль район Башлыгына, айлык акчалата бүләкләүдән һәм еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән тыш, айлык акчалата бүләкләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләр өстәмә түләнергә, шулай ук

муниципаль хокук актлары нигезендә башка түләүләр дә башкарылырга мөмкин. Шул ук вакытта муниципаль район Башлыгына акчалата түләүләрнең айлык җыелма күләме Татарстан Республикасы министрына акчалата түләүләрнең 0,9 айлык җыелма күләменнән артмаска тиеш.

2.3. Муниципаль район Башлыгына акчалата түләүнең 2,5е күләмендә айлык акчалата бүләүләү түләнелә.

2.4. Муниципаль район Башлыгы урынбасарына, айлык акчалата бүләкләүдән һәм еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән тыш, айлык акчалата бүләкләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләр өстәмә түләнергә, шулай ук муниципаль хокук актлары нигезендә башка түләүләр дә башкарылырга мөмкин. Шул ук вакытта муниципаль район Башлыгы урынбасарына акчалата түләүләрнең айлык җыелма күләме муниципаль район Башлыгына акчалата түләүләрнең 0,55 айлык җыелма күләменнән артмаска тиеш.

2.5. Муниципаль район Башлыгы урынбасарына акчалата түләүнең 1,14е күләмендә айлык акчалата бүләкләү түләнелә.

2.6. Муниципаль район Контроль-исәп палатасы рәисенә, айлык акчалата бүләкләүдән һәм еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән тыш, айлык акчалата бүләкләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләр өстәмә түләнергә, шулай ук муниципаль хокук актлары нигезендә башка түләүләр дә башкарылырга мөмкин. Шул ук вакытта аларга акчалата түләүләрнең айлык җыелма күләме муниципаль район Башлыгы урынбасарына акчалата түләүләрнең 0,39 айлык җыелма күләменнән артмаска тиеш.

2.7. Муниципаль район Контроль-исәп палатасы рәисенә акчалата түләүнең 0,5е күләмендә айлык акчалата бүләкләү түләнелә.

2.8. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга матди ярдәм елга бер айлык акчалата бүләкләү күләмендә хезмәт хакы фондында экономия булганда түләнә. Матди ярдәм еллык түләүле ял биргәндә хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә түләнә. Еллык түләүле ял өлешләп бирелгәндә матди ярдәм, гариза нигезендә бер тапкыр, күрсәтелгән ялның теләсә кайсы өлешен биргәндә түләнә. Гариза нигезендә матди ярдәм календарь ел дәвамында түләнелә ала.

2.9. Муниципаль район Башлыгына, муниципаль район Башлыгы урынбасарына, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайлап куела торган органнары әгъзаларына, муниципаль район Контроль-исәп палатасы рәисенә еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү бер айлык акчалата бүләкләүдән артмаган күләмдә түләнә.

## 3. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү.

3.1. Муниципаль хезмәткәрнең акчалата тулы кереме Нигезләмә белән билгеләнгән үзе биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килә торган хезмәт хакыннан (алга таба – вазыйфаи хезмәт хакы), шулай ук айлык һәм башка өстәмә түләүләрдән (алга таба – өстәмә түләүләр) тора.

3.2. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмнәре Саба муниципаль районы Советы карары белән билгеләнә.

3.3. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмнәре авыл җирлегендәге муниципаль хезмәт вазыйфаларына караган кече төркем белгеченең 11 163 сум тәшкил иткән вазыйфаи хезмәт хакы күләменнән чыгып исәпләнә.

3.4. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи хезмәт хакларын исәпләгәндә кулланыла торган коэффициентлар 1нче кушымтада билгеләнә.

3.5. Айлык һәм башка өстәмә түләүләргә керәләр:

3.5.1. **тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә.** Тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә түләү түбәндәгеләрдән артмаган күләмдә билгеләнә:

| Муниципаль хезмәт стажы | Өстәмә күләме, процентларда |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 10 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 15 |
| 15 елдан югары | 20 |

3.5.2. **класс чины өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә түбәндәгеләрдән артмаган күләмдә билгеләнә:**

| Класс чины | класс чины өчен өстәмә түләү күләме (вазыйфаи хезмәт хакына карата процентларда) |
|---|---|
| 1 | 2 |
| I класслы гамәли муниципаль киңәшче | 7 |
| II класслы гамәли муниципаль киңәшче | 5 |
| III класслы гамәли муниципаль киңәшче | 3 |
| I класслы муниципаль киңәшче | 7 |
| II класслы муниципаль киңәшче | 5 |
| III класслы муниципаль киңәшче | 3 |
| I класслы муниципаль хезмәт киңәшчесе | 7 |
| II класслы муниципаль хезмәт киңәшчесе | 5 |
| III класслы муниципаль хезмәт киңәшчесе | 3 |
| I класслы муниципаль хезмәт референт | 7 |
| II класслы муниципаль хезмәт референт | 5 |
| III класслы муниципаль хезмәт референт | 3 |
| I класслы муниципаль хезмәт секретаре | 7 |
| II класслы муниципаль хезмәт секретаре | 5 |
| III класслы муниципаль хезмәт секретаре | 3 |

3.5.3. **муниципаль хезмәтнең махсус шартлары (катлаулылык, киеренкелек, хезмәттә ирешкән югары казанышлар, махсус эш режимы) өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә.** Муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен җирле үзидарә җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә түләү түбәндәгеләрдән артмаган күләмдә билгеләнә:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары өчен – вазыйфаи хезмәт хакының

9 процентыннан;

муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары өчен - вазыйфаи хезмәт хакының 7 процентыннан;

муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары өчен - вазыйфаи хезмәт хакының 5 процентыннан;

муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары өчен - вазыйфаи хезмәт хакының 3 процентыннан;

муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары өчен - вазыйфаи хезмәт хакының 1 процентыннан;

3.5.4. **айлык акчалата бүләкләү**. Муниципаль хезмәткәргә вазыйфаи хезмәт хакының 1 процентыннан артмаган күләмдә айлык акчалата бүләкләү билгеләнә.

3.5.5. **аеруча мөһим һәм катлаулы эшләр башкарган өчен.** Муниципаль хезмәткәрләрнең эш нәтиҗәлелеген, җирле үзидарә органнарына йөкләнгән вәкаләтләрне үтәүдә җаваплылык дәрәҗәсен арттыру, үтәлә торган эшнең сыйфатын яхшырту, вазыйфаи тәгълимнамә белән каралган вазыйфаи бурычларын үз вакытында һәм намус белән үтәүне тәэмин итү максатларында, муниципаль хезмәткәргә хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә максималь күләм белән чикләнмәгән премия билгеләнә. Премияне түләү тәртибе эш бирүче (эш кушучы) вәкиле тарафыннан муниципаль орган бурычларын һәм функцияләрен, вазыйфаи тәгълимнамәне үтәүне тәэмин итүне исәпкә алып билгеләнә.

3.5.6. **Еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү.** Еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү муниципаль хезмәткәргә агымдагы финанс елында бер тапкыр 1,2 вазыйфаи хезмәт хакыннан артмаган күләмдә түләнә.

Бер тапкыр бирелә торган түләү муниципаль хезмәткәрнең шәхси гаризасы нигезендә еллык түләүле ял (аның бер өлешен) биргәндә агымдагы финанс елында бер тапкыр түләнә.

Календарь ел дәвамында муниципаль хезмәткәргә еллык түләүле ял бирелмәсә, аңа бер тапкыр бирелә торган түләү декабрь аенда эшләгән вакытына пропорциональ исәпләнә һәм түләнә, муниципаль хезмәткәр эштән киткән очракта – хезмәт килешүе туктатылган көннән дә соңга калмыйча түләнә.

Еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү муниципаль хезмәтнең беренче елы өчен календарь елда эшләгән вакытына пропорциональ түләнә. Эшләгән вакыт муниципаль хезмәткә кергән көннән агымдагы календарь елның 31 декабрен кертеп исәпләнә.

3.5.7. **матди ярдәм.** Матди ярдәм беренчел профсоюз органының үтенеч язуы буенча җирле үзидарә органы җитәкчесе ихтыяры белән түләнергә мөмкин. Матди ярдәм хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә түләнә. Матди ярдәм түләүгә җирле үзидарә органы җитәкчесе боерыгы нигез булып тора.

Матди ярдәм түбәндәге очракларда түләнә:

– бала туганда – 5000 сум күләмендә;
– якын туганнарны күмгәндә – 3000 сум күләмендә;

Ата-ананың икесе дә хезмәт эшчәнлеген Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарында эшләсә, матди ярдәм ата-ананың берсенең гаризасы буенча түләнә.

Матди ярдәм түләгәндә якын туганнарга ир (хатын), ата-аналар һәм балалар, шулай ук ирнең (хатынның) ата-анасы керә.

Матди ярдәм җирле үзидарә органы җитәкчесе боерыгы нигезендә бирелә. Матди ярдәм хезмәт өчен түләүнең әлеге җирле үзидарә органы өчен билгеләнгән фонды исәбеннән түләнә.

3.6. Муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесенең вазыйфаи хезмәт хакы күләме муниципаль хокукый актлар нигезендә билгеләнә. Монда муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесенә айлык акчалата түләү муниципаль район Башлыгына акчалата түләүләрнең 0,6 айлык җыелма күләменнән арта алмый.

## 4. Муниципаль район башлыгына, муниципаль район башлыгы урынбасарына, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайлап куела торган органнары әгъзаларына, муниципаль районның Контроль-хисап палатасы рәисенә акчалата бүләк, муниципаль хезмәткәрләрнең айлык акчалата тулы керемен түләү тәртибе

4.1. Муниципаль район башлыгына, муниципаль район башлыгы урынбасарына, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайлап куела торган органнары әгъзаларына, муниципаль районның Контроль-хисап палатасы рәисенә акчалата бүләк, муниципаль хезмәткәрләрнең акчалата тулы керемен түләү (текстта алга таба - муниципаль вазыйфа биләүче затларга һәм муниципаль хезмәткәрләргә) сумнарда башкарыла. Айлык акчалата түләү һәм айлык акчалата тулы керем түләү (алга таба текст буенча – акчалата бүләк һәм акчалата тулы керем) вакытында эш бирүче муниципаль вазыйфа биләгән затларга һәм һәр муниципаль хезмәткәргә тиешле чорга аңа исәпләнгән хезмәт хакының состав өлешләре, тотып калынган акчаларның күләмнәре һәм нигезләре турында язма рәвештә хәбәр итәргә, шулай ук түләнергә тиешле гомуми акчалата сумма турында хәбәр итәргә тиеш. Хисап кәгазе формасы эш бирүче тарафыннан раслана.

4.2. Муниципаль вазыйфа биләүче затларга акчалата бүләк һәм муниципаль хезмәткәрләргә акчалата тулы керемне түләү, шулай ук айлык һәм башка өстәмә түләүләрне күләме арттыру ягына таба бер сумга кадәр түгәрәкләнергә тиеш.

## 5. Муниципаль хезмәткәрләргә премия түләү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәткәрләргә аеруча мөһим һәм катлаулы эшләр башкарган өчен премия түләү (алга таба – премия) тиешле җирле үзидарә органының бурычларын һәм функцияләрен тәэмин итүне исәпкә алып эш нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органы җитәкчесенең әлеге Нигезләмәгә туры китереп кабул ителгән боерыгы белән башкарыла. Премия түләү өчен җирле үзидарә органы җитәкчесенең боерыгы нигез булып тора.

5.2. Хезмәткәрләрнең гомуми эш нәтиҗәләренә керткән шәхси өлешенә тәңгәл китереп, аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән, хезмәткәрләрнең истәлекле даталарына бер тапкыр бирелә торган премия күләме чикләнми.

5.3. Премияләр хисап чорында муниципаль хезмәткәр хезмәт дисциплинасын бозган өчен дисциплинар һәм матди җаваплылыкка тартылган очракта түләнми:

- эшкә килмәү;
- соңга калу;
- турыдан-туры җитәкче боерыгын үтәмәү;
- эштә алкоголь, наркотик, токсинлы исереклек халәтендә килү;
- эш бирүче милкен югалту яки зыян китерү;
- билгеләнгән хезмәт нормаларын үтәмәү, йөкләмәләр үтәү срокларын бозу.

5.4. Муниципаль хезмәткәрнең алынмаган дисциплинар җәзасы булганда премия күләме 50% ка кими.

5.5. Әгәр хезмәт дисциплинасын бозулар премияне түләгәннән соң ачыкланса, премия дисциплина бозу ачыкланган хисап чорында киметелә.

## 6. Саба муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру

6.1. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү фондын формалаштырганда вазыйфаи окладлар түләү өчен җибәрелә торган акчалар суммасыннан тыш, түләү өчен түбәндәге акчалар карала (елына 12 вазыйфаи окладтан чыгып):

1) класс чины өчен айлык өстәмә – вазыйфаи хезмәт хакының 4 процентыннан артмаган күләмдә;

2) муниципаль хезмәттә тиешле елларны эшләгән өчен айлык өстәмә - вазыйфаи хезмәт хакының 13 процентыннан артмаган күләмдә;

3) муниципаль хезмәтнең махсус шартлары (катлаулылык, киеренкелек, хезмәттә ирешкән югары казанышлар, махсус эш режимы) өчен айлык өстәмә - вазыйфаи хезмәт хакының 5 процентыннан артмаган күләмдә;

4) аеруча мөһим һәм катлаулы эшләр башкарган өчен премия - вазыйфаи хезмәт хакының 1 процентыннан артмаган күләмдә;

5) айлык акчалата бүләкләү - вазыйфаи хезмәт хакының 1 процентыннан артмаган күләмдә;

6) еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү - вазыйфаи хезмәт хакының 10 процентыннан артмаган күләмдә;

## 7. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затка, шулай ук Саба муниципаль районы муниципаль хезмәткәренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә, бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкне түләү тәртибе

7.1. Муниципаль вазыйфадан азат ителгәндә һәм бу чорда пенсия яшенә җиткән яисә эшкә сәләтлелеген югалткан очракта, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә пенсиягә өстәмә хокук булганда, муниципаль вазыйфаны биләгән затка биләгән вазыйфасы буенча билгеләнгән айлык акчалата бүләкләүнең ун тапкыр арттырылган күләмендә бер тапкыр акчалата бүләк түләнә.

7.2. Муниципаль вазыйфа биләгән затка бер тапкыр бирелә торган бүләкләү вәкаләтләрне «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы ның 6 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты “а” – “и” пунктчаларында каралган нигезләр буенча туктатканда түләнми.

7.3. Муниципаль вазыйфа биләгән затка бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкне түләү өчен җирле үзидарә органы эштән азат ителгән көннән соң 5 календарь көн дәвамында Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына түбәндәге документларны тапшыра:

– вәкаләтләрне туктату һәм бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләне түләү турында карар (карарлар) күчермәсе;

– муниципаль вазыйфа биләгән затның айлык акчалата бүләкләве турында белешмә;

– җирле үзидарә органы җитәкчесе һәм кадрлар хезмәте тарафыннан расланган муниципаль вазыйфада, дәүләт һәм муниципаль хезмәттә эшләү стажы турында белешмә;

– җирле үзидарә органының кадрлар хезмәте тарафыннан расланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе;

– җирле үзидарә органы җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан расланган бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкнең исәп-хисабы.

7.4. Муниципаль хезмәткәргә тиешле елларны эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә муниципаль хезмәттән азат ителгәндә, муниципаль хезмәт стажы 15 елга тулса, муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча эштән азат ителгән көнгә билгеләнә торган айлык акчалата тулы кеременең биш тапкыр арттырылган күләмендә һәм муниципаль хезмәтнең киләсе һәр тулы елы өчен – өстәмә рәвештә 0,5 сум күләмендә, әмма муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата тулы кеременең ун тапкырдан да артмаган күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк түләнә. Муниципаль хезмәт стажы муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итү көненә билгеләнә.

7.5. Әлеге Тәртип максатларында тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу дип картлык буенча хезмәт пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә җиткәннән яки «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә инвалидлык буенча пенсия билгеләү буенча муниципаль хезмәттән

эштән азат ителүне, муниципаль хезмәткәрнең гаепле гамәлләренә бәйле эштән азат ителүдән тыш һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу өчен кирәкле муниципаль хезмәт стажы булу күзаллана.

7.6. Бер тапкыр бирелә торган бүләкләү күләмен билгеләгәндә исәпкә алына торган айлык акчалата тулы керем составына кертелә:

– вазыйфаи хезмәт хакы;
– муниципаль хезмәттә тиешле елларны эшләгән өчен айлык өстәмә;
– класс чины өчен айлык өстәмә;
– муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен вазыйфаи хезмәт хакына өстәмә түләү муниципаль хезмәткәр эштән азат ителгән көнгә кадәр 6 айдан да ким булмаган күләмдә билгеләнгән күләмдә;
– еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү 1/12күләме;

7.7. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турындагы карар муниципаль хезмәткәрнең шәхси гаризасы нигезендә эш бирүче (эшкә яллаучы вәкиле) тарафыннан кабул ителә һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрне эштән азат итү турында җирле үзидарә органы карары кабул ителү белән бер үк вакытта рәсмиләштерелә.

7.8. Бер тапкыр бирелә торган бүләк эш бирүче (муниципаль хезмәткәр хезмәт иткән органның яллаучысы вәкиле) муниципаль хезмәткәр эштән азат ителгәнче бер айдан да соңга калмыйча түләнә.

7.9. Муниципаль хезмәткәр эштән азат ителгән көнгә кадәр 30 календарь көн кала җирле үзидарә органы (муниципаль орган) тарафыннан бер тапкыр бирелә торган бүләкләү күләмен билгеләү өчен Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (алга таба – финанс-бюджет палатасы) түбәндәге документларны тапшыра:

– муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата тулы кереме турында белешмә;
– муниципаль хезмәттә эшләү стажы турында җитәкче һәм кадрлар хезмәте тарафыннан расланган белешмә;
– хезмәт кенәгәсе һәм хәрби билетының кадрлар хезмәте раслаган күчермәләре;
– класслы чин бирү, муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата тулы кереме составына керүче вазыйфаи хезмәт хакына өстәмәләр билгеләү турында приказлардан өземтә;
– җирле үзидарә органы җитәкчесе һәм баш хисапчысы тарафыннан расланган бер тапкыр бирелә торган бүләк исәп-хисабы;
– дисциплинар җәза булмавы турында белешмә.

7.10. Бер тапкыр бирелә торган бүләк түләнми:

– эштән китү вакытына алынмаган дисциплинар җәзасы булган муниципаль хезмәткәргә;
– дәүләт граждан хезмәте турындагы закон нигезендә тиешле елларны эшләгән өчен дәүләт пенсиясенә чыгу белән бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк түләнгән муниципаль хезмәткәргә.

7.11. Финанс-бюджет палатасы, муниципаль орган документлар тапшырганнан соң 20 көн эчендә, аңа бюджет ассигнованиеләре һәм муниципаль вазыйфа биләгән затка яисә муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган бүләкләү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары турында белдерүне яисә әлеге тәртиптә каралган барлык документлар тапшырылмаган очракта муниципаль органга бер тапкыр бирелә торган бүләкләүне түләү өчен акча бирүдән мотивацияләнгән баш тартуны җиткерә. Җирле үзидарә органы әлеге белдерү нигезендә 10 көн эчендә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк түләүне башкара.

7.12. Финанс-бюджет палатасы муниципаль вазыйфа биләгән затка яисә муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган бүләкләү түләү өчен бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары булмаган очракта, җирле үзидарә органы документлар тапшырганнан соң 5 эш көне эчендә Саба муниципаль районы Советына муниципаль вазыйфа биләгән затка яисә муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган бүләкләү түләү өчен район бюджетыннан акча бүлеп бирү турындагы карар проектын җибәрә.

7.13. Саба муниципаль районы Советы карары кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә финанс-бюджет палатасы җирле үзидарә органына бюджет ассигнованиеләре турында һәм муниципаль вазыйфа биләгән затка яки муниципаль хезмәткәргә пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләүләүне түләү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары турында белдерү хаты җиткерә.

7.14. Җирле үзидарә органы әлеге белдерү хаты нигезендә Саба муниципаль районы Советы тарафыннан муниципаль вазыйфа биләгән затка яки муниципаль хезмәткәргә пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкне түләү өчен район бюджетыннан акча чыганаклары бүлеп бирү турында карар кабул ителгәннән соң бер айдан соңга калмыйча муниципаль вазыйфа биләгән затка яки муниципаль хезмәткәргә пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкне түли.

7.15. Җирле үзидарә органы әлеге белдерү хаты нигезендә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкне түли.

**8. Муниципаль хезмәткәр вафат булган очракта бер тапкыр бирелә торган пособие түләү тәртибе**

8.1. Муниципаль хезмәткәр вафат булган очракта, аның гаиләсенә элек биләгән вазыйфасы буенча еллык акчалата тоту күләмендә бер тапкыр бирелә торган пособие түләнә (алга таба – бер тапкыр бирелә торган пособие). Күрсәтелгән пособиене түләү тәртибе һәм шартлары Саба муниципаль районы Советы карары белән билгеләнә.

8.2. Муниципаль хезмәткәр вафат булган очракта бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләгәндә исәпкә алына торган еллык акчалата керем составына кертелә:

- вазыйфаи хезмәт хакы;
- тиешле еллар эшләгән өчен өстәмә;

– класслы чин өчен өстәмә;
– еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү 1/12күләме.

8.3. Эш бирүче тарафыннан бер тапкыр бирелә торган пособие (муниципаль хезмәткәр хезмәт иткән орган вәкиле) ире (хатыны) яки берәр баласы яки ата-анасына аларның гаризасы буенча түләнә.

8.4. Җирле үзидарә органы гариза кергән көннән алып 5 календарь көн эчендә бер тапкыр бирелә торган пособие күләмен билгеләү өчен финанс-бюджет палатасына түбәндәге документларны тапшыра:

– муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата тулы кереме турында белешмә;
– кадрлар хезмәте раслаган хезмәт кенәгәсенең күчермәләре;
– класслы чин бирү, тиешле еллар эшләгән өчен өстәмә түләү билгеләү турында приказлардан өземтә;
– муниципаль хезмәткәрнең үлеме турында таныклык;
– җирле үзидарә органы җитәкчесе һәм баш хисапчысы тарафыннан расланган бер тапкыр бирелә торган пособиенең исәп-хисабы.

8.5. Бер тапкыр бирелә торган пособие түләү максатларында гамәлләр финанс-бюджет палатасы һәм җирле үзидарә органы тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 7.11 – 7.15 пунктларында каралган тәртиптә башкарыла.

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы депутатларының, җирле үзидарә органнарының сайлап куела торган вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезләмәгә
1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хакларын исәпләгәндә кулланыла торган коэффициентлар таблицасы

| № | Вазыйфа исеме | Коэффициентлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 2 |
| 2 | Башкарма комитет Җитәкчесе | 2,60 |
| 3 | Башкарма комитет Җитәкчесенең Беренче урынбасары | 2,36 |
| 4 | Вәкиллекле орган аппараты җитәкчесе (эшләр идарәчесе) | 2,36 |
| 5 | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары | 2,34 |
| 6 | Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе | 2,33 |
| 7 | Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе урынбасары | 2,14 |
| 8 | Башкарма комитет аппараты җитәкчесе (эшләр идарәчесе) | 2,19 |
| 9 | Башкарма комитет аппараты идарәсе начальнигы | 1,90 |
| 10 | Башкарма комитетның мөстәкыйль бүлеге начальнигы (мөдире), башка структур бүлекчәсе (аппараты) җитәкчесе, тикшерү органы аудиторы | 1,82 |
| 11 | Башкарма комитет аппараты идарәсе начальнигы урынбасары | 1,80 |
| 12 | Башкарма комитетның мөстәкыйль бүлеге начальнигы (мөдире) урынбасары, башка структур бүлекчәсе (аппараты) җитәкчесе урынбасары | 1,59 |
| 13 | Муниципаль район Башлыгы ярдәмчесе, Башкарма комитет Җитәкчесе ярдәмчесе, муниципаль район Башлыгы киңәшчесе, Башкарма комитет Җитәкчесе киңәшчесе | 1,59 |
| 14 | Башкарма комитет идарәсе составындагы бүлек начальнигы | 1,59 |
| 15 | Сектор мөдире | 1,47 |
| 16 | Баш белгеч | 1,41 |
| 17 | Әйдәп баручы белгеч | 1,31 |
| 18 | 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 1,20 |

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Советының
09.04.2018 ел, 208 номерлы карарына
1нче кушымта

**Саба муниципаль районы Башлыгы, җирле үзидарәнең Саба муниципаль районында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, Саба муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисенең айлык акчалата бүләкләү күләмнәре**

| Вазыйфа исеме | акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль район Башлыгы | 29 555 |
| Муниципаль район Башлыгы урынбасары | 26 600 |
| Депутатлар | 14 492 |
| Җирле үзидарәнең сайлап куела торган органнары әгъзалары | 12 314 |
| Муниципаль районның Контроль-хисап палатасы рәисе | 26 600 |